ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**12.03.2018**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 532**

2013 елның 1 октябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2220 номерлы карарына һәм 2018 елның 01 февралендәге«Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы балаларга мәгариф учреждениеләренә йөрүче балаларга компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында» 200 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 1 октябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2220 номерлы карарының 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. «ЗМР БК финанс-икътисад хезмәте» МКУ һәм Зеленодольск муниципаль районында республика матди ярдәм үзегенең 21 нче бүлеген компенсация түләүләре өчен вәкаләтле орган белән билгеләргә».

2. Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 01 февралендәге«Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы балаларга мәгариф учреждениеләренә йөрүче балаларга компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында» 200 номерлы карарының 2 пункты гамәлдә түгел дип танылды һәм үз көчен югалтты.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәренең Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин